**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОМСОМОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«20» январенде 2025ел № 01

2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^{1}$ статьясы 32 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген яңа редакциядә расларга (1кушымта).
2. Әлеге карар 2025 елдан башлап һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә кулланыла дип билгеләргә.
3. «2024 елга һәм 2025, 2026 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 5 февралендәге 03 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан 2025 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә һәм Тукай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе О.В. Сурова

ОГРН 1061682004988
р 08-157/09
Исполнительный комитет Комсомольского сельского поселения
ИНН 1639032411

Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның «20» январенде 01 номерлы карарына кушымта

2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына
Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге

Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге

| Керемнәрнең баш администраторы | Бюджет керемнәре | Исеме |
|---|---|---|
| бюджет классификациясе коды | | |

**Тукай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы**

| | | |
|---|---|---|
| 170 | 1 16 01074 01 0000 140 | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7 бүлегендә билгеләнгән муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан ачыкланган милекне саклау өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар |
| 170 | 1 16 01084 01 0000 140 | Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан ачыкланган әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар |
| 170 | 1 16 01074 01 0000 140 | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7 бүлегендә билгеләнгән милек саклау өлкәсендә муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары ачыкланган административ хокук бозулар өчен административ штрафлар |

**Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы**

| | | |
|---|---|---|
| 605 | 1 08 04020 01 1000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы түләү суммасы (тиешле түләү, шул исәптән юкка чыгарылган түләү |

| | | |
|---|---|---|
| | | буенча яңадан исәпләүләр, недоимка һәм бурыч) |
| 605 | 1 08 04020 01 4000 110 | Җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (башка кертемнәр) |
| 605 | 1 08 07175 01 1000 110 | Җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләрне ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларының автомобиль юллары буйлап хәрәкәтенә махсус рөхсәт биргән өчен җирлекләр бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы |
| 605 | 1 08 07175 01 4000 110 | Җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр һәм (яисә) эре габаритлы йөкләрне ташучы транспорт чараларының автомобиль юллары буйлап хәрәкәтенә махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы |
| 605 | 1 11 02033 10 0000 120 | Авыл җирлекләре бюджетларының вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан керемнәр |
| 605 | 1 11 03050 10 0000 120 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчалары хисабына ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар |
| 605 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган<br>керемнәр |
| 605 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) башка керемнәр |
| 605 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 605 | 1 14 02053 10 0000 440 | Авыл җирлекләре милкендәге башка мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 605 | 1 16 07010 10 0000 140 | Муниципаль орган, авыл җирлегенең казна учреждениесе тарафыннан төзелгән муниципаль контрактта каралган йөкләмәләрне җиткерүче (подрядчы, башкаручы) тарафыннан үтәү срогы чыккан очракта, штрафлар, неустойкалар, пенялар |

| | | |
|---|---|---|
| 605 | 1 16 10031 10 0000 140 | Файда күрүчеләр авыл җирлеге бюджеты акчаларын алучылар булган иминият очраклары барлыкка килгәндә зыянны каплау |
| 605 | 1 16 10032 10 0000 140 | Авыл җирлеге муниципаль мөлкәтенә (муниципаль бюджет (автоном) учреждениеләренә, унитар предприятиеләргә беркетелгән мөлкәттән тыш) китерелгән зыянны башка каплау |
| 605 | 1 16 11064 01 0000 140 | Авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташый торган транспорт чаралары тарафыннан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелгән зыянны каплау максатында түләнә торган түләүләр |
| 605 | 1 16 02020 02 0000 140 | Муниципаль хокукый актларны бозган өчен Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар |
| 605 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 605 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларының салым булмаган башка керемнәре |
| 605 | 1 17 14030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары |
| 605 | 2 02 15001 10 0000 150 | Бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 605 | 2 02 15002 10 0000 150 | Бюджетларның баланслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 605 | 2 02 30024 10 0000 150 | Россия Федерациясе субъектларының тапшырыла торган вәкаләтләрен үтәүгә авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 605 | 2 02 35118 10 0000 150 | Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр |
| 605 | 2 02 35930 10 0000 150 | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 605 | 2 02 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 605 | 2 04 05020 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларга бирелә торган акчалата иганәләрдән керемнәр |
| 605 | 2 07 05020 10 0000 150 | Физик затлар тарафыннан авыл җирлекләре бюджетларыннан акча алучыларга бирелә торган акчадан кергән акчалардан керемнәр |

| | | |
|---|---|---|
| 605 | 2 07 05030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр |
| 605 | 2 08 05000 10 0000 150 | Артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар суммаларын һәм артык түләтелгән суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтаруны (исәпкә алуны) гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (җирлекләр бюджетларына) күчерүләр |
| 605 | 2 18 60010 10 0000 150 | Узган еллардагы максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтарудан авыл җирлекләре бюджетлары керемнәре |
| 605 | 2 18 60020 10 0000 150 | Узган еллардагы максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларыннан кире кайтарудан авыл җирлекләре бюджетлары керемнәре |
| 605 | 2 19 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары кабул иткән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның калган өлешләрен авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтар |
| 605 | 2 19 60010 10 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган башка субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калдыкларын авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| 605 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотация |
| 605 | 2 02 49999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар |
| 605 | 2 02 40014 10 0000 150 | Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 605 | 2 08 10000 10 0000 150 | Түләтү өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл җирлекләре бюджетларына) күчерүләр |